**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*Юрид.адрес: 423984, РТ, Муслюмовский район, с.Октябрь, ул.Молодежная, д.3а,*
*Факт.адрес: 423984, РТ, Муслюмовский район, с.Октябрь, ул.Центральная, д.33А*
E-mail Okt.Mus@tatar.ru *тел. 8(8-5556) 3-51-26*
ИНН 1629004040, КПП 162901001, ОГРН 1021687005346, ОКАТО 92242860001

Октябрь авылы «07» апрель 2021 ел

**РЕШЕНИЕ** **№ 12** **КАРАР**

**«Октябрь авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» Октябрь авыл җирлеге Башкарма комитетының 17.02.2017 ел, 2 нче номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Төп муниципаль актка үзгәрешләр кертә торган муниципаль акттагы хаталарны төзәтү зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Октябрь авыл җирлеге Башкарма комитетының 17.02.2017нче елгы, 2 нче номерлы карары белән расланган «Октябрь авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6.2 пунктының соңгы абзацын төшереп калдырырга;

1.2. 2.8 пунктының соңгы абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.9 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.»;

1.4 3.3 пунктының 2) пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2) ведомствоара гаризнамәләр җибәрә:

салым органында исәпкә кую, салым, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар барлыгы (юклыгы) турында Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Октябрь авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе:** **И.М.Ханнанов**